ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 18 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $8^2$ статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының $1^2$ өлеше, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 3 өлеше нигезендә җирлекләрнең, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарының (алга таба – җирле үзидарә органнары) шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүлә.

2 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирле үзидарә органнарының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары җирлекнең җирле үзидарә органнарының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге түбәндәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар:

1) генераль план проектын әзерләү турында карар, шулай ук генераль планга үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр әзерләү турында карар кабул итү;

2) генераль план проектын әзерләү, генераль планны раслау, шул исәптән генераль планга үзгәрешләр кертү;

3) территориаль планлаштыруның һәм шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документын әзерләү һәм раслау, шул исәптән мондый бердәм документка үзгәрешләр кертү;

4) җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү турында карар, шулай ук җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында проект әзерләү турында яисә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне кире кагу турында карар кабул итү;

5) җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү;

6) шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

7) җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү турында йә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту хакында карар кабул итү;

8) рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында йә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту хакында карар кабул итү;

9) территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында карар кабул итү;

10) территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү, территорияне планлаштыру документларын раслау, шул исәптән территорияне планлаштыру документларына үзгәрешләр кертү;

11) җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә төзелешкә рөхсәт, объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү;

12) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү, теркәү һәм бирү;

13) территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итү һәм аны гамәлгә ашыру;

14) җир кишәрлекләре һәм (яисә) аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары хокукына ия булучыларның инициативасы буенча гамәлгә ашырыла торган территорияне комплекслы үстерү турында шартнамәләр төзү.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары муниципаль районның җирле үзидарә органнарының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге түбәндәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар:

1) муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасын әзерләү турында карар, шулай ук мондый схемага үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр әзерләү турында карар кабул итү;

2) муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасы проектын әзерләү, муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасын раслау, шул исәптән мондый схемага үзгәрешләр кертү;

3) шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

4) территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында карар кабул итү;

5) территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү, территорияне планлаштыру документларын раслау, шул исәптән территорияне планлаштыру документларына үзгәрешләр кертү;

6) әлеге өлеш нигезендә яңадан бүленә торган вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасын алып бару һәм мондый дәүләт мәгълүмат системасындагы белешмәләрне, документларны һәм материалларны бирү.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары шәһәр округының җирле үзидарә органнарының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге түбәндәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар:

1) генераль план проектын әзерләү турында карар, шулай ук генераль планга үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр әзерләү турында карар кабул итү;

2) генераль план проектын әзерләү, генераль планны раслау, шул исәптән генераль планга үзгәрешләр кертү;

3) территориаль планлаштыруның һәм шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документын әзерләү һәм раслау, шул исәптән мондый бердәм документка үзгәрешләр кертү;

4) җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү турында карар, шулай ук җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында проект әзерләү турында яисә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне кире кагу турында карар кабул итү;

5) җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү;

6) шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

7) җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү турында йә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту хакында карар кабул итү;

8) рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында йә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту хакында карар кабул итү;

9) территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында карар кабул итү;

10) территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү, территорияне планлаштыру документларын раслау, шул исәптән территорияне планлаштыру документларына үзгәрешләр кертү;

11) шәһәр округы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә төзелешкә рөхсәт, объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү;

12) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү, теркәү һәм бирү;

13) территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итү һәм аны гамәлгә ашыру;

14) җир кишәрлекләре һәм (яисә) аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары хокукына ия булучыларның инициативасы буенча гамәлгә ашырыла торган территорияне комплекслы үстерү турында шартнамәләр төзү;

15) әлеге өлеш нигезендә яңадан бүленә торган вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасын алып бару һәм мондый дәүләт мәгълүмат системасындагы белешмәләрне, документларны һәм материалларны бирү.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2, 3, 5, 7, 8 һәм 10 пунктларында, 2 өлешендәге 5 пунктында һәм 3 өлешендәге 2, 3, 5, 7, 8 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча җәмәгать фикер алышулары һәм гавами тыңлаулар вәкаләтләре әлеге Закон белән яңадан бүленә торган җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үткәреләләр.

5. Авария хәлендә дип танылмаган һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле булмаган һәм күпфатирлы йортны торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турындагы карарга кертү мәсьәләсе буенча торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү хакындагы карар проектына кертелгән күпфатирлы йортлар милекчеләренең гомуми җыелышлары вәкаләтләре әлеге Закон белән яңадан бүленә торган җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үткәреләләр.

3 статья. **Җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре яңадан бүленә торган срок**

Әлеге Законның 2 статьясындагы 1 – 3 өлешләрендә күрсәтелгән җирле үзидарә органнары вәкаләтләре чикләнмәгән срокка яңадан бүленә.

4 статья. **Әлеге Закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү**

1. Әлеге Закон белән яңадан бүленә торган вәкаләтләр архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге вәкаләтле республика башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге Закон белән яңадан бүленә торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибе, яңадан бүленә торган вәкаләтләрне башкарганда, шул исәптән җирле үзидарә органнары фикерен исәпкә алу максатларында, җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында хезмәттәшлек тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3. Әлеге Закон белән яңадан бүленә торган вәкаләтләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 2 статьясындагы 3 өлешеннән тыш, 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 2 статьясындагы 3 өлеше 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Закон үз көченә кергәнче әзерләү йә үзгәрешләр кертү турында карарлар кабул ителгән, шулай ук әлеге Закон үз көченә кергәнче аларга карата Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган килештерү процедуралары башланган муниципаль районнарның территориаль планлаштыру схемалары, җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары, җирлекләрнең, шәһәр округларының территориаль планлаштыруның һәм шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары, территорияне планлаштыру документлары җирле үзидарә органнары тарафыннан әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган тәртиптә раслана.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 23 декабрь
№ 131-ТРЗ